**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 15 июль № 514

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыру турында» 2006 ел, 17 май, 249 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Иң яхшы укытучыларны акчалата бүләкләүгә конкурс үткәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 ел, 6 апрель, 362 нче боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проектын гамәлгә ашыру турында» 2006 ел, 17 май, 249 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2008 ел, 7 июль, 468 нче; 2008 ел, 18 декабрь, 893 нче; 2009 ел, 22 июнь, 420 нче; 2010 ел, 13 август, 646 нчы; 2011 ел, 4 август, 632 нче; 2012 ел, 7 март, 196 нчы; 2012 ел, 31 май, 457 нче; 2013 ел, 20 август, 580 нче; 2014 ел, 14 февраль, 86 нчы; 2014 ел, 22 май, 344 нче; 2015 ел, 2 февраль, 52 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 нче пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс нигезендә сайлап алу кагыйдәләрендә:

1.2 нче пунктның икенче абзацындагы «республиканың шәһәр һәм авыл җирлегендә урнашкан белем бирү оешмаларында укучылар санын исәпкә алып» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Конкурсны үткәрү өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын сайлап алу буенча республика конкурс комиссиясен (алга таба – конкурс комиссиясе) төзи.

Конкурс комиссиясе составына конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешеннән артмаган санда белем бирү оешмалары җитәкчеләре, конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешеннән артмаган санда эш бирүчеләр һөнәри берләшмәләре вәкилләре, конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешеннән артмаган санда эшчәнлекләрен мәгариф өлкәсендә гамәлгә ашыручы иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре һәм конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән бер өлешеннән артмаган санда белем бирү оешмаларында укучыларның ата-аналары (законлы вәкилләре) керә.»;

2.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Конкурс комиссиясе иң яхшы укытучыларны конкурс нигезендә сайлап алуны түбәндәге критерийлар буенча үткәрә:

укыта торган предмет буенча, һөнәри берләшмәдә апробацияләү нәтиҗәләре буенча уңай бәяләнгән үз методик эшләнмәң булу;

соңгы өч елда укучыларның укудагы казанышларының уңай динамикасы күзәтелгәндә югары нәтиҗәләр;

уку предметы буенча укучыларның дәрестән тыш эшчәнлегенең югары нәтиҗәләре;

укучыларның уңай социаль тәҗрибә алуы өчен, аларның гражданлык позициясен формалаштыру өчен укутучының шартлар тудыруы;

укучыларның төрле категорияләре (сәләтле балалар, социаль яктан имин булмаган гаиләләрдәге балалар, тормышта авыр хәлдә калган балалар, мигрантлар гаиләсеннән булган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, инвалид балалар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар, девиант тәртипле (иҗтимагый яктан куркыныч) балалар) белән адреслы эшләү өчен укутучының шартлар тудыруы;

төрле белем бирү технологияләреннән, шул исәптән дистанцион белем бирү технологияләреннән яки электрон укытудан нәтиҗәле файдалану нигезендә уку-укыту процессын оештыруның югары сыйфатын тәэмин итү;

укытучының өзлексез профессиональ үсеше.»;

3.2 нче, 3.3 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Әлеге Кагыйдәләрнең 1.3 нче пунктында күрсәтелгән укытучыларны акчалата бүләкләүгә тәкъдим итү (алга таба – Дәгъвачылар) аларның ризалыгы белән белем бирү оешмасының коллегиаль идарә органы (алга таба – Гариза бирүчеләр) тарафыннан башкарыла. Гариза бирүченең укытучыны конкурска тәкъдим итү турындагы тәкъдимнамәсе әлеге Кагыйдәләргә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча төзелә.

3.3. Конкурс комиссиясе түбәндәгеләр нигезендә конкурста катнашучыларны терки:

белем бирү оешмасы коллегиаль идарә органының укытучыны тәкъдим итү турындагы карарының (карарыннан өземтәнең) күчермәсе;

укытучының тиешле һөнәри белеме дәрәҗәсе турында белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган документның күчермәсе;

укытучының белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган һәм әлеге Кагыйдәләрнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары нигезендә формалаштырылган, укытучының һөнәри казанышлары турында кәгазьдәге һәм (яки) электрон мәгълүмат;

педагогик эшчәнлек нәтиҗәләрен җәмәгатьчелеккә һәм һөнәри берлеккә халык алдында тәкъдир итү турында мәгълүмат (дөреслеге документлар белән расланган булырга тиеш).

Күрсәтелгән документлар, шулай ук башка материаллар (кирәк булган очракта) Дәгъвачы тарафыннан конкурс комиссиясенә кертелә һәм әлеге Кагыйдәләргә теркәлгән 2 нче кушымта нигезендәге документлар исемлеге буенча кабул ителә.

Конкурс комиссиясенә тапшырылган документлар Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының архивында кимендә 5 ел саклана һәм, күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң, Дәгъвачыга кире кайтарыла, кайтарырга мөмкин булмаган очракта юк ителә.»;

3.6 нчы пункттагы «, Совет һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килештерелә һәм җәмәгатьчелек игътибарына җиткерелә» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.7 нче, 3.8 нче пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

3.10 нчы пункттагы «Совет тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проекты буенча совет тарафыннан (алга таба – Совет)» сүзләренә алыштырырга;

3.16 нчы пункттагы «Советка» сүзен «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына»;

3.17 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.17 Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан хупланган конкурста җиңүчеләр исемлеге Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгына агымдагы елның 10 июненнән соңга калмыйча җибәрелә.»;

әлеге Кагыйдәләргә теркәлгән 2 – 4 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс нигезендә сайлап алу кагыйдәләренә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс нигезендә сайлап алу

______________________________________________

| |
|---|
| Теркәү саны: _______________<br>Заявканы теркәү көне: _______________ |

**Республика конкурс комиссиясенә катнашу критерийлары буенча экспертиза үткәрү өчен укытучы тарафыннан тапшырылган документлар**
**исемлеге**

| Т/с | Документ / конкурс материалы исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Гариза бирүченең укытучыны иң яхшы укытучылар конкурсына тәкъдим итү турындагы тәкъдимнамәсе | |
| 2. | Белем бирү оешмасы коллегиаль идарә органының укытучыны тәкъдим итү турындагы карарының (карарыннан өземтәнең) күчермәсе | |
| 3. | Укытучының тиешле һөнәри белеме дәрәҗәсе турындагы документның күчермәсе (белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган) | |
| 4. | Укытучының хезмәт кенәгәсе күчермәсе (белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган) | |
| 5. | Укытучының һөнәри казанышлары турында мәгълүмат (белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган) | |
| 6. | Укытучының педагогик эшчәнлеге нәтиҗәләрен җәмәгатьчелеккә һәм һөнәри берлеккә халык алдында тәкъдир итүне раслаучы беркетмә (эш бирүче тарафыннан расланган) | |

Барлыгы _____________ бит.

**Өстәмә конкурс материаллары**

| Т/с | Документ / конкурс материалы исеме | Битләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Укытучының паспорты күчермәсе (фотосурәт һәм теркәү күрсәтелгән битләр) | |
| 2. | Укытучы эшли торган белем бирү оешмасын аккредитацияләү турындагы таныклык күчермәсе | |
| 3. | Башка документлар (конкурста катнашучы инициативасы буенча) (беркетмәләр, сертификатлар, таныклыклар, дипломнар һ.б.) | |

Барлыгы_____________ бит.

Тапшырды (Ф.И.А.и., вазыйфасы, эш урыны): ___________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
Имза: _____________________
Дата: ________________________

Кабул итте (Ф.И.А.и., вазыйфасы, эш урыны): ___________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
Имза: _____________________
Дата: ________________________

Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс нигезендә сайлап алу кагыйдәләренә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен
конкурс нигезендә сайлап алу

---

Теркәү саны: ________________
Заявканы теркәү көне: ________________

**Республика конкурс комиссиясенә**
**укытучы тарафыннан тапшырылган документларга техник экспертиза бәяләмәсе**

| Т/с | Документ / конкурс материалы исеме | Кабул ителде (әйе) | Кабул ителмәде (юк) |
|---|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүченең укытучыны иң яхшы укытучылар конкурсына тәкъдим итү турындагы тәкъдимнамәсе | әйе | юк |
| 2 | Белем бирү оешмасы коллегиаль идарә органының укытучыны тәкъдим итү турындагы карарының (карарыннан өземтәнең) күчермәсе | әйе | юк |
| 3 | Тиешле һөнәри белем дәрәҗәсе турындагы документның күчермәсе (белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан раслан-ган) | әйе | юк |
| 4 | Хезмәт кенәгәсе күчермәсе (белем бирү оешмасы җитәкчесе та-рафыннан расланган) | әйе | юк |
| 5 | Укытучының һөнәри казанышлары турында мәгълүмат (белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан расланган) | әйе | юк |
| 6 | Укытучының педагогик эшчәнлеге нәтиҗәләрен җәмәгатьчелек-кә һәм һөнәри берлеккә халык алдында тәкъдир итүне раслаучы беркетмә (эш бирүче тарафыннан расланган) | әйе | юк |

| Техник экспертиза нәтиҗәсе | |
|---|---|
| Техник экспертиза нәтиҗәләре буенча конкурста катнашырга рөхсәт ителде | Техник экспертиза нәтиҗәләре буенча конкурста катнашырга рөхсәт ителмәде |

Эксперт ________________/______________________ дата __________________
Республика конкурс комиссиясе рәисе:
_____________________/________________________________

Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларын акчалата бүләкләү өчен конкурс нигезендә сайлап алу кагыйдәләренә
4 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ИҢ ЯХШЫ УКЫТУЧЫЛАРЫН АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ ӨЧЕН КОНКУРС НИГЕЗЕНДӘ САЙЛАП АЛУ**

**Теркәү саны**: ____________

**ЭКСПЕРТ БӘЯЛӘМӘСЕ**

| Т/с | Сайлап алу критерийлары | Эксперт-ның йомгак баллы | Эксперт имзасы | Эксперт-ның йомгак баллы | Эксперт имзасы | Эксперт-ның йомгак баллы | Эксперт имзасы | Критерий буенча йомгак балл |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** |
| 1 | Укыта торган предмет буенча, һөнәри берләшмәдә апробацияләү нәтиҗәләре буенча уңай бәяләнгән үз методик эшләнмәң булу | | | | | | | |
| 2 | Соңгы өч елда укучыларның укудагы казанышларының уңай динамикасы күзәтелгәндә югары нәтиҗәләр | | | | | | | |
| 3 | Уку предметы буенча укучыларның дәрестән тыш эшчәнлегенең югары нәтиҗәләре | | | | | | | |
| 4 | Укучыларның уңай социаль тәҗрибә алуы өчен, аларның гражданлык позициясен формалаштыру өчен укутучының шартлар тудыруы | | | | | | | |
| 5 | Укучыларның төрле категорияләре (сәләтле балалар, социаль яктан имин булмаган гаиләләрдәге балалар, тормышта авыр хәлдә калган балалар, мигрантлар гаиләсеннән булган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, инвалид балалар һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар, девиант тәртипле (иҗтимагый яктан куркыныч) балалар белән адреслы эшләү өчен укутучының шартлар тудыруы | | | | | | | |
| 6 | Төрле белем бирү технологияләреннән, шул исәптән дистанцион белем бирү техно- | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | логияләреннән яки электрон укытудан нәтиҗәле файдалану нигезендә уку-укыту процессын оештыруның югары сыйфатын тәэмин итү | | | | | | | |
| 7 | Укытучының өзлексез профессиональ үсеше | | | | | | | |
| | **Гомуми балл** | | | | | | | |

**Эксперт**:

_____________________/_______________________/ **Дата**________________»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проекты буенча совет составында:

Совет составыннан М.Ф.Алексеевны, С.В.Гыйниятуллинаны, П.Г.Данилаевны, А.В.Климинны, В.А.Песошинны чыгарырга;

Совет составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Илгиз Ирек улы Җәләлевны | урта һөнәри белем бирүче «П.В.Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллияте» дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе директорын |
| Татьяна Сергеевна Камалетдинованы | «Татарстан Республикасының Мәгълүмати технологияләр үзәге» дәүләт унитар предприятиесе башкарма директорын |
| Айдар Марат улы Каюмовны | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын |
| Игорь Сергеевич Вершининны | югары һөнәри белем бирүче «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең компьютер системалары кафедрасы мөдире (килешү буенча); |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проекты буенча совет турындагы нигезләмәдә:

2.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Үзенә йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен, Совет, өстенлекле «Мәгариф» илкүләм проектын тормышка ашыру кысаларында, талантлы яшьләргә ярдәм итү йөзеннән премияләр бирүгә кандидатларны сайлап ала.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков